ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2024 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 525-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Л.А. Якунин һәм К.Ә. Ногаев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2024 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 525-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 15 феврале
№ 2344-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Л.А. Якунин, К.Ә. Ногаев
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2024 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2024 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» 2023 елның 4 декабрендәге 118-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2023, № 92 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлештә «чыгым йөкләмәләренә» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясе Президентын сайлауларны әзерләүдә һәм үткәрүдә ярдәм күрсәтүгә бәйле чыгым йөкләмәләренә һәм гражданнарга социаль ярдәм чараларын финанс белән тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабиненты (җирле администрация) тарафыннан ачыкланган 2024 елның 1 гыйнварына кадәр билгеләнгән чыгым йөкләмәләренә» сүзләрен өстәргә;

2) 2 өлештә «өстәмә чараларны» сүзләреннән соң «, шулай ук Россия Федерациясе Президентын сайлауларны әзерләүдә һәм үткәрүдә ярдәм күрсәтүгә бәйле чараларны» сүзләрен өстәргә;

3) 3 өлештә «өстәмә чараларны» сүзләреннән соң «, шулай ук Россия Федерациясе Президентын сайлауларны әзерләүдә һәм үткәрүдә ярдәм күрсәтүгә бәйле чараларны» сүзләрен өстәргә;

4) 4 өлештә «өстәмә чараларны» сүзләреннән соң «, шулай ук Россия Федерациясе Президентын сайлауларны әзерләүдә һәм үткәрүдә ярдәм күрсәтүгә бәйле чараларны» сүзләрен өстәргә;

5) 6 өлештә «өстәмә чараларны» сүзләреннән соң «, шулай ук Россия Федерациясе Президентын сайлауларны әзерләүдә һәм үткәрүдә ярдәм күрсәтүгә бәйле чараларны» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан  көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2024 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2024 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 628-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) кабул ителүгә бәйле рәвештә эшләнде.

Федераль закон 2024 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгели:

Россия Федерациясе Президентын сайлауларны әзерләүдә һәм үткәрүдә ярдәм күрсәтүгә бәйле чаралар һәм гражданнарга социаль ярдәм чараларын финанс белән тәэмин итү буенча Россия Федерациясе субъектының иң югары башкарма хакимияте (җирле администрация) тарафыннан ачыкланган 2024 елның 1 гыйнварына кадәр билгеләнгән чыгым йөкләмәләре өлешендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә кертелмәгән чыгым йөкләмәләрен кабул итү мөмкинлеге;

регионнарның һәм муниципаль берәмлекләрнең дәүләт (муниципаль) бурычын һәм бурыч кытлыгын Россия Федерациясе Президентын сайлауларны әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле чыгымнары күләменә арттыра алу мөмкинлеге.

Югарыда бәян ителгәннәргә бәйле рәвештә закон проекты белән «Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2024 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» 2023 елның 4 декабрендәге 118-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2024 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалтуы танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы закон актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2024 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы закон актларының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчен югалтуын тану, туктатып тору, үзгәртү яисә кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2024 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын финас-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2024 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.